ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2019 п.г.т. Алексеевское №11

**“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 5 июль, 2018 ел, 69 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы 2 май, 2006 ел, № 59-ФЗ санлы Федераль закон, “Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм “Россия Федерациясендә алга китешле социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында”гы Федераль законның 22 нче маддәсе, 2 нче өлеше, 2 нче пунктының көчен югалтуы турында”гы 27 декабрь, 2018 ел, 528-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә миграция һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен оештырып кору уңаеннан һәм гамәлдәге законнарга туры китерү максатында

**карар бирде:**

1. ”Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 5 июль, 2018 ел, 69 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 10 нчы пункты, 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә игълан итәргә:

2. Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын һәртөрле бозу фактлары турында мәгълүмат язылган язма мөрәҗәгать теркәлгәннән соң биш көн эчендә эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм мөрәҗәгать җибәргән гражданинның аның мөрәҗәгатен бүтән адреска җибәрү турындагы белдерүе белән, шушы Тәртипнең 7.7 өлешендә күрсәтелгән очрактан кала, Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

3. Район Советы аппаратының гомуми бүлегенә әлеге карарның күчермәсен барлык кызыксындырылган затларга җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә, шулай ук Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга. Адрес: ТР, Алексеевск районы, Совет мәйданы, 1 нче йорт.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Алексеевск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.С. Харитоновка йөкләргә..

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**